**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**

**Әлкәй авыл җирлеге Советы карары**

Әлкәй авылы № 113 10.10.2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советы 28.10.2011 №11 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең муниципаль милектәге мөлкәтне арендага бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең норматив хокукый актларының «Конкуренцияне яклау турында» Федераль законның 17_1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 04.06.2018 №135-ФЗ Федераль законга туры китерү максатларында

Әлкәй авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советы 28.10.2011 №11 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең муниципаль милектәге мөлкәтне арендага бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертергә, 3.1 пунктының унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үткәрелгән конкурс яисә аукцион нәтиҗәләре буенча дәүләт яисә муниципаль контракт төзелгән затка, әгәр күрсәтелгән хокукларны әлеге дәүләт яисә муниципаль контрактны үтәү максатларында аукцион турында документлар, документация белән каралган булса, яисә дәүләт яисә муниципаль автоном учреждениеse белән конкурс яки аукцион нәтиҗәләре буенча «Юридик затларның аерым төрләренең товарлар, эшләр, хезмәтләр закупкалары турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үткәрелгән шартнамә яисә аукцион төзегән затка, әгәр күрсәтелгән хокукларны әлеге шартнамәне үтәү өчен документация сатып алу максатлары каралган булса. Мондый мөлкәткә күрсәтелгән хокукларны бирү срогы дәүләт яисә муниципаль контрактны йә шартнамәне башкару срогыннан артмаска тиеш;».

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo. tatarstan.ru. һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http//aznakayevo. tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис С.З.Зиннурова